**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 гыйнвар № 44

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының сатып алуларда катнашуын күздә тоткан Россия Федерациясе законнары таләпләренә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарының, инновацион продукция, югары технологик продукция, дару чаралары, сатып алу планнарының, мондый планнарга кертелгән үзгәрешләрнең туры килүен мониторинглау үткәрү, мондый планнар проектларының, мондый планнарга кертелә торган үзгәрешләр проектларының туры килүен бәяләү тәртибе, мондый бәяләү һәм мониторинглау нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән планнарны тормышка ашыруны туктатып тору тәртибе һәм вакытлары турында» 2015 ел, 29 октябрь, 1169 нчы карарын үтәү һәм Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү тармагында дәүләт җайга салуын тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1.82.2, 4.1.82.3 пунктлар өстәргә:

«4.1.82.2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының сатып алуларда катнашуын күздә тоткан Россия Федерациясе законнары таләпләренә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарының, инновацион продукция, югары технологик продукция, дару чаралары, сатып алу планнарының, мондый планнарга кертелгән үзгәрешләрнең, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәгаен заказчыларның туры килүен бәяләүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә оештыра һәм гамәлгә ашыра.

4.1.82.3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының сатып алуларда катнашуын күздә тоткан Россия Федерациясе законнары таләпләренә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу планнарының, инновацион продукция, югары технологик продукция, дару чаралары, сатып алу планнарының, мондый планнарга кертелгән үзгәрешләрнең, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан сатып алулар турында еллык хисапларның, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән аерым заказчылардан инновацион продукция, югары технологик продукция сатып алу турында еллык хисапларның туры килүен мониторинглауны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә оештыра һәм гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 60 көн эчендә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль законда каралган туры килүне бәяләү һәм туры килүне мониторинглау нәтиҗәләре буенча кул кую тәртибен раслау һәм бәяләмәләрне һәм йомгакларны раслау турында норматив хокукый акт проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\44.docx